РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

РУКОВОДИТЕЛЬ
Исполнительного комитета
Азнакаевского
муниципального района

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
башкарма комитеты
ҖИТӘКЧЕСЕ

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«__21__» ____03____ 2019 ел** **№ ___63___**

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, РФ төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 19 декабрендәге 822/пр номерлы боерыгы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Азнакай муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданы бәясе нормативы турында» 23.019 ел, № 13 карары белән, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының үзара бәйләнеше турында» гы карары нигезендә **карар чыгарам:**

1. 2019 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тануга карар чыгару өчен түбәндәге чикләрне билгеләргә :

Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1 Ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 523 610 сум;

1.1.2 Ике кешедән торган гайлә өчен – 1 939 140 сум;

1.1.3 Өч кешедән торган гайлә өчен – 2 493 180 сум;

1.1.4 1.1.4 Дүрт кешедән торган гайлә өчен – 3 324 240 сум;;

1.1.5 Биш кешедән торган гайлә өчен – 4 155 300 сум;;

1.1.6 Алты кешедән торган гайлә өчен – 4 986 360 сум;

1.1.7 Җиде кешедән торган гайлә өчен – 5 817 420 сум;;

1.1.8 Сигез кешедән торган гайлә өчен – 6 648 480 сум;

1.1.10Тугыз кешедән торган гайлә өчен – 7 479 540 сум;

1.1.11 Ун кешедән торган гайлә өчен – 8 310 600 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме тәшкил итә:

1.2.1 Ялгыз яшәүче граждан өчен – 16484,50 сум;

1.2.2 Ике кешедән торган гайлә өчен – 10490,13 сум;

1.2.3 Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гайлә өчен – 8991,54 сум.

2. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының исәп һәм хисап бүлеге әлеге карар имзаланганнан соң 10 көн эчендә әлеге карарны рәсми басма – «Маяк» газетасында, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов